| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

26.10.2021 Казан ш. № 3261-р

**Газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) саклау зонасын үзгәртү һәм Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 15.12.2014 № 2881-р карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56 ст., «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 13 июль 2015 ел № 218-ФЗ Федераль законның 32 ст., Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен, һәм «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате һәм газ бүлү челтәрләренә милек хокукын раслаучы документлар нигезендә, һәм «Күчемсез милек кадастры» ҖЧҖ башкарган документациягә туры китереп, «Татарстан Республикасының пространство мәгълүматлары фонды» дәүләт бюджет учреждениесе хатын исәпкә алып (04.10.2021 № 1256/05), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы) КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Питрәч районында урнашкан, «Газпром трансгаз Казань» (ЭПУ «Приволжскгаз») милке булган, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасының Питрәч муниципаль районы һәм Казан шәһәре (өлешчә) территориясендә газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) саклау зоналары чикләрен раслау турында” 15.12.2014 № 2881-р карары (алга таба - № 2881-р Карар) белән урнаштырылган 4437 м. озынлыктагы газ бүлү челтәре объектларының («Бүлүче газүткәргечләрнең саклау зонасы, инв. 29261,

инв. 9556») 16:33:180201:1012, 16:33:180201:1063 кадастр номерлы җир кишәрлекләре өлешләрендәге саклау зонасын бетерергә.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы территориясендә «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ милкендә булган 4381,5 м озынлыктагы газ бүлү челтәре объектларының («Газ бүлү газүткәргечләренең саклау зонасы, инв. 29261, инв. 9556»), түбән басымлы газүткәргечләрне күчерү сәбәпле, «Күчемсез милек кадастры» ҖЧҖ 2021 елның мартында әзерләгән территорияне куллануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текст һәм график тасвирламасында булган белешмәләр, җир асты һәм җир өсте объектлары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге буенча 16:33:180201:1012, 16:33:180201:1063 кадастр номерлы җир кишәрлекләрендәге саклау зоналарын урнаштырырга.

3. Әлеге карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән һәм өлешчә яки тулысынча күрсәтелгән газүткәргечләрнең саклау зонасына туры килгән җир кишәрлекләренә 29261, 9556 инвентарь номерлы газүткәргечләрнең эксплуатация срогында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

4. «Күчемсез милек кадастры» ҖЧҖ әзерләгән территорияне куллануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текст һәм график тасвирламасында булган белешмәләр, җир асты газүткәргеч чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге нигезендә № 2881-р карарга (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының от 21.07.2017 № 1709-р, 15.10.2018 № 3420-р карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының Питрәч муниципаль районы һәм Казан шәһәре (өлешчә) территориясендә газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) саклау зоналарын урнаштыру турында»;

1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) саклау зоналарын урнаштырырга»;

1 пунктның 1.1. подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. «Земля» республика кадастр үзәге» АҖ, «Күчемсез милек кадастры» ҖЧҖ тарафыннан әзерләнгән территорияне куллануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текст һәм график тасвирламасында булган белешмәләр, җир өсте һәм җир асты объектлары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге нигезендә, «Приволжскгаз» ЭПУның Татарстан Республикасы Питрәч районы территориясендә урнашкан 375,5975 км озынлыктагы, әлеге карарның 1 нче кушымтасында күрсәтелгән инвентарь номерлы газ бүлү газүткәргече.»;

1 нче кушымтада:

29261, 9556 инвентарь номерларына туры килгән юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «114 | 29261, 9556 | | Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге | 4381,5 | d = 160 түбән басым | 16:24-6:2001-233.1 02.11.2001»; |

2 нче кушымтада:

29261, 9556 инвентарь номерларына туры килгән юлны төшереп калдырырга;

әлеге карарга 1 нче кушымтадагы юллар белән тудыландырырга.

5. Әлеге карарның башкарылуын контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары А.И.Галиевка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**

Татарстан Республикасы Җир һәм
мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
от 27.10.2021 № 3261-р карарына
1 нче кушымта

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| "29261, 9556 | ТР, Питрәч МР, Шигалм ав.с. Яңа Шигали ав., Советская ур., з/у 11 | Эшмәкәрлек | | 16:33:180201:1012 | Торак пунктлар җирләре | 249,81 | Бухарова Антонина Васильевна | Эшмәкәрлек |
| 29261, 9556 | ТР, Питрәч МР, Шигалм ав.с. Яңа Шигали ав., Советская ур. | шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару | | 16:33:180201:1063 | Торак пунктлар җирләре | 82,30 | Бухарова Антонина Васильевна | шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару |